РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 7 декабре № 54

Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 59 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма йөкләмәләрен үтәвен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 59 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың йөкләмәләрен үтәвен муниципаль контрольдә тотуны гамәлгә ашыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешманың җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча йөкләмәләрен үтәвенә муниципаль контрольне Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты яисә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында төзелгән килешүгә ярашлы рәвештә башка җирле үзидарә органы тарафыннан башкарыла (алга таба – контроль органы).»;

1.6 пунктны түбәндәге эчтәлектәге сүзләр белән тулыландырырга:

«, яки Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында төзелгән килешүгә ярашлы рәвештә җирле үзидарәнең башка җаваплы кешесенә.»;

Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымта) бәян итәргә.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.Х. Муллин

Түбән Кама шәһәр
Советының 2023 елның
7 декабрендәге
54 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама шәһәре территориясендә
җылылык белән тәэмин итү объектларын
төзү, реконструкцияләү һәм (яки)
модернизацияләү буенча бердәм
җылылык белән тәэмин итүче оешманың
йөкләмәләрен үтәвен муниципаль
контрольдә тоту буенча Нигезләмәгә
2нче кушымта

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контроль чараларын үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы күрсәткечләре

1. Контроль орган адресына җылылык энергиясен кулланучылардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, мәҗбүри хокук бозулар фактлары турында массакүләм мәгълүмат чараларыннан килгән алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда, вакыт берәмлегендә (ай, алты ай, унике ай) мөрәҗәгатьләр санының ике тапкыр һәм аннан да күбрәк артуы «Җылылык белән тәэмин итү турында»27.07.2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр.

2. Две и более аварии, произошедшие на одних и тех же объектах теплоснабжения в течение трех месяцев подряд.

2. Бер үк җылылык объектларында өч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк авария булганда.

Түбән Кама шәһәре Мэры
урынбасары

М.В. Камелина